**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры**
**_____________ И.Г.Һадиуллин**

**«___»_____________ 2024 нче ел**

# Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен 2025 нче елда туган (татар) телдән бердәм республика имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения единого республиканского экзамена 2025 года по родному (татарскому) языку для обучающихся школ с родным языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Туган телдә белем бирү оешмалары укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтихан эшен башкару өчен 210 минут вакыт бирелә. Әлеге вакыт эчендә укучылар 3 өлештән торган эшне башкарып чыгарга тиеш.

Беренче өлеш 30 биремне (1–30) үз эченә ала. Һәр биремгә тәкъдим ителгән 4 вариант җавапның берсен, ягъни дөресен генә сайлап алырга кирәк.

Икенче өлеш 8 биремнән (31–38) гыйбарәт. Бу биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга кирәк.

Өченче өлештә сезгә бер бирем (39) тәкъдим ителә. Сез бирелгән текст буенча инша язарга тиешсез.

Биремнәрне күрсәтелгән тәртиптә үтәргә киңәш итәбез. Аларны үтәү барышында кыенлык тудырганы килеп чыккан очракта, әлеге биремне калдырып торып, алдагысына күчегез. Вакыт калса, бу биремнәргә кабат әйләнеп кайта аласыз.

Дөрес җавап, катлаулылыгыннан чыгып, бер яки югарырак балл белән бәяләнә. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Уңышлар телибез!**

## 1 нче өлеш

***1-30 нчы биремнәрнең җавабы сан белән күрсәтелә. Җавапларны 1 нче номерлы җавап бланкына, кирәкле бирем номерыннан уң якка, беренче шакмактан башлап язып куярга кирәк.***

**1.** Түбәндәге җөмләдәге *пешү* сүзенең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән очракны күрсәтегез.

*Әһә, эш пешә болай булгач дип, кулларны угаладым.*

1) пешерелгән хәлгә килү
2) югары температура тәэсирендә тән, тире җәрәхәтләнү
3) җайлану, көйләнү, барып чыгу
4) өлгерү, җитлегү

**2.** Берлек санда, барлыкта, кайтым юнәлешендә, III зат тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендәге исем фигыль кулланылган җөмләне күрсәтегез.
1) Югалтуның ни икәнен белми, юатуны белми һич йөрәк.
2) Минем бурыч – хәзер шуларны түкми-чәчми укучыларга җиткерү.
3) Син килүнең файдасы шул булды: печән вакытында җыелды.
4) Булат мондый салкын каршы алынуына аптырап, урындыкка утырды.

**3.** Татар теленең орфографик нормаларына туры килмәгән сүз язылган җөмләне күрсәтегез.
1) Ул, сихерләнеп, түбәндә йөзгән ак томан болытларына карап тора.
2) Болгар дәүләте күп әйберләр белән сәүдә иткән.
3) Иң элек идеялар сандыгын эшләдек: конкурста катнашучылар ике төркемгә бүленеп, проектлар язалар.
4) Күтәрелгән саен тау сырты куе томаннан арына бара иде.

**4.** Сөйләм сафлыгына зыян китерә торган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.
1) Ул үзен дөньядагы иң бәхетле кеше сыман тойды.
2) Гали ерактан ишетелгән пычкы тавышына сискәнеп китте.
3) Сугыш беткәнгә дә ел ярым үтеп бара.
4) Башлыйбызмы инде концертны, наканис!

**5.** Әдәби тел нормаларына туры килмәгән сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.
1) Сөйләгәнен без тын да алмый тыңлыйбыз.
2) Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы буенча тулы метражлы кинофильм төшерелде.
3) Көтелмәгән хәбәрдән башы әйләнгән вакытта күзе тәрәзәгә төште.
4) Синең кылмышың кайберәүләрнең күңеленә хуш ятмастыр.

***Текстны укыгыз һәм 6-11 нче биремнәрне үтәгез.***

1) ... 2) Монда иске авыл эзләрен күрсәтеп торган бернәрсә дә юк. 3) Авыл уртасыннан боргаланып-сыргаланып агым су үтә. 4) Шунда шатлана-шатлана бәбкәләре белән казлар, үрдәкләр һәм нәни балалар коена. 5) Су буена алмагачлар, чия һәм шомырт агачлары тезелгән. 6) Яз көннәрендә авыл ап-ак чәчкәләргә күмелә. 7) Авыл өстенә хуш ис <...> аромат җәелә. 8) Күрше таулардан чишмәләр ага. 9) Тау өстендә урман шаулый. 10) Авылдан бер километрда урман эчендә ял йорты урнашкан. 11) Ял йортының якты тәрәзәләре, ..., безне дәшеп тора. 12) Ак тасмадай сузылган таш юлдан йөк һәм җиңел машиналар йөри.

13) Авылның җәйге күренеше әнә шул төстә ...

(*Г. Кутуйдан*)

**6.** Текстның беренче җөмләсе булып килергә тиешле җөмләне күрсәтегез.
1) Җәйге авыл хәтирәсе...
2) Бу авыл миңа бик ошады.
3) Авыл иртәсе бу.
4) Ял йортына барам.

**7.** 11 нче җөмләдәге күп нокталар урынына туры килгән сүзне күрсәтегез.
1) сыман
2) мөгаен
3) һичшиксез
4) әйтерсең

**8.** 7 нче җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиеш тыныш билгесен күрсәтегез.
1) сызык
2) ике нокта
3) нокталы өтер
4) өтер

**9.** Җөмләләрнең оештыручы үзәге дөрес күрсәтелгән очракны күрсәтегез.
1) авыл эзләрен (2 нче җөмлә)
2) таулардан ага (8 нче җөмлә)
3) урман шаулый (9 нчы җөмлә)
4) урман эчендә урнашкан (10 нчы җөмлә)

**10.** Текстның 5 нче җөмләсендәге *алмагачлар* сүзенең басымы дөрес күрсәтелгән очракны күрсәтегез.
1) алмагачлАр
2) Алмагачлар
3) алмагАчлар
4) алмАгачлар

**11.** 9 нчы җөмләнең төрен күрсәтегез.
1) гади, җәенке, тулы, бер составлы хикәя җөмлә
2) гади, җәенке, тулы, ике составлы, хикәя җөмлә
3) гади, җыйнак, тулы, ике составлы, хикәя җөмлә
4) тезмә кушма җөмлә

**12.** Түбәндә бирелгән сүзтезмәләр арасыннан янәшә тору юлы белән бәйләнгән сүзтезмәне күрсәтегез.
1) әнинең күлмәге
2) урманга бару
3) түгәрәк күл
4) урамнан керү

**13.** Җөмләдә аерып бирелгән җөмлә кисәгенең төрен күрсәтегез.

***Шатлыгыннан*** *аның күзләре ут кебек янды.*

1) аергыч
2) тәмамлык
3) аныклагыч
4) сәбәп хәле

**14.** Каршы кую интонациясе ярдәмендә теркәлгән тезмә кушма җөмләне күрсәтегез.
1) Рәшит яшертен генә баскыч ягына карап алды – менүче кеше күренмәде.
2) Тынычлык, иминлек шулай бик кадерле, ул безнең халыкның рухына сеңгән иде.
3) Аның янында кемнәрдер бар, ә эти арттан атлый.
4) Вакыйга болай булган: Нәгыймә ханым көндезге икеләрдә өенә кайткан.

**15.** Сөйләм төгәллеге бозылган җөмләне күрсәтегез.
1) Мин эткәйнең сөйләвенә, аның нәрсә белән кызыксынуына гаҗәпсенеп барам.
2) Әгәр эшкә файдасы булса, без түзәргә дә әзер.
3) Казанга Җәлил юбилее тантаналарына килгән күпсанлы делегацияләрне чын күңелдән сәламлибез.
4) Һәм алар уйладылар: ничек шәһәрдә һәм авылда яшәгән татар яшьләрен бәйләргә.

**16.** Морфологик принципка буйсынып язылган очракны күрсәтегез.
1) механизм
2) утырганга
3) драмтүгәрәк
4) вазифа

**17.** Сүзләр аерым язылырга тиешле очракны күрсәтегез.
1) эш куар, ил басар
2) чыктылы керделе, аллы артлы
3) төн боек, таш күмер
4) риза булу, хөрмәт итү

**18.** ъ билгесе аеру вазифасын башкарган очракны күрсәтегез.
1) мәгънә
2) игътибар
3) кульяулык
4) ягъни

**19.** *акварель* сүзенә дөрес кушымча ялганган очракны күрсәтегез.
1) акварельлар
2) акварельга
3) акварелене
4) акварельны

**20.** Күп нокталар урынына ике бертөрле хәреф языла торган очракны күрсәтегез.
1) тәвә...әл
2) фә...ыйрь
3) ха...ият
4) китап...анә

**21.** Ике сүздә дә *һ* хәрефе язылырга тиешле очракны күрсәтегез.
1) җи...ан, ...иммәтле
2) ..əвəс, и..тыяр
3) зин...ар, и..лас
4) ...әвәскәр, ми..нәт

**22.** *–ар* кушымчасы ялганырга тиешле очракны күрсәтегез.
1) кал-
2) уз-
3) батыр-
4) тарал-

**23.** Җөмләдә сызык куелырга тиешле очракны күрсәтегез (тыныш билгеләре куелмаган).
1) Алар акыртын гына кары тыгызланган урман юлы буйлап киттеләр.
2) Юк миңа аның җырларын тыңлау гына аз.
3) Була шундый минутлар хәтта дустыма булган зур үпкә дә тиз онытыла.
4) Синең атаң зирәкләрнең зирәге.

**24.** Җөмләдә <...> тамгасы урынына тыныш билгесенең куелышы дөрес аңлатылган очракны күрсәтегез.

*Бүлмә тулы әйбер <...> комод, көзге, шкаф, сәгать, тагын әллә нәрсәләр. (Х. Сарьян)*

1) тиңдәш кисәкләр үзара санау интонациясе белән килгәнлектән, биредә өтер куела.
2) тиңдәш кисәкләрне санап китү көтелгәнлектән, биредә ике нокта куела.
3) каршы кую интонациясе белән әйтелгәнлектән, биредә тиңдәш кисәкләр янына сызык куела.
4) тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүз килгәнлектән, биредә сызык куела.

**25.** Аерымланган рәвеш хәле кулланылган җөмләне билгеләгез (тыныш билгеләре куелмаган).

1) Ул катерны кире җибәрү ниятеннән баржада килгән йөкне тизрәк бушатырга кушты.
2) Көннәр бераз җылытканнан соң Камил Ак чишмәдән умарталык өенә күчкән иде.
3) Хәлим аяк очларына басып тәрәзәдән карады.
4) Фәйрүзә әйттеме егылып үлсә дә әйткән сүзеннән чигенми иде.

**26.** Тезмә кушма җөмләдә сызык куелырга тиешле очракны билгеләгез (тыныш билгеләре куелмаган).

1) Бу арада ни хаты килми ни хәбәре юк.
2) Хәрәкәтсез калып тыңлап торган солдатлар кузгалышып куйдылар тик берсе дә тынлыкны бозмады.
3) Эшләгән тук булган ә эшләмәгән юк булган.
4) Авыл янында партизаннарны күренүе булды фашистлар коралларын ташлап кача да башладылар.

**27.** Җөмләдә куелырга тиешле тыныш билгесен күрсәтегез (тыныш билгеләре куелмаган).

*Кабинетыма кереп чишенергә дә өлгермәдем яңадан ишек шыгырдады.*

1) өтер
2) нокталы өтер
3) сызык
4) ике нокта

***Текстны укыгыз һәм 28-30, 31-38, 39 нчы биремнәрне эшләгез.***

1) Гөл күтәреп килеп чыккан Җиһан әбине мин күтәренке күңел белән, шатланып көтеп алдым. 2) Ул да мине күрде, тыйнак кына елмаеп, ерактан ук башын кагып куйды. 3) Таеп егылмасын дип, аны подъезд төбенә кадәр барып алдым. 4) Гөленә үрелгән идем дә, бирмәде. 5) Артык ялынмадым, үзе беләдер әле дип, аның бу кирелеген эчемнән генә үткәреп җибәрдем.

6) – Менә шулай көн саен чыгып йөрибез... 7) Мин торган якка кояш карамый бит, көн яктысы төшми.

8) Юк, зарланмый иде Җиһан әби. 9) Гомумән, зарлана белми, ахры, бу карчык. 10) Аның һәр сүзе дога кебек ягымлы чыга. 11) Хәтта зары да... 12) Нindидер чиста, ягымлы, иманлы карчык бу. 13) Нигә элгәрерәк белмәдем икән мин аны? 14) Бик кызык, гаҗәеп матур дөньяда яши бугай ул. 15) Нindидер якты, илаһи бер халәттә...

16) – Сез миңа шушы гөлегез хакында сөйләргә булган идегез... 17) Аны тере дип тә әйттегез әле...

18) – Әә, әйе шул. 19) Әллә ни зур сере юк аның. 20) Ә менә җаны хакында дөрес әйттем. 21) Тере гөл бу. 22) Кешеләрдәге кебек, аның да җаны бар, күңеле бар, кайгысы-зары, шатлыгы бар...

23) – Каян беләсез соң аны, Җиһан әби?

24) – Күзләренә карап...

25) – Ничек инде? Гөлләрнең күзләре буламыни?

26) – Була шул. 27) Их сез, яшьләр... 28) Якыннарыгызның күзенә тутырып карарга да вакытыгыз юк бит сезнең. 29) Ә һәр үләннең, һәр үсемлекнең, гөлнең, чишмәнең, елганың, тауның, кояш-йолдызларның күзенә карарга бөтенләй дә вакытыгыз калмый... 30) Менә кара әле бу чәчәкләргә... 31) Менә таҗларына, керфекләренә кара... 32) Ул керфекләр арасыннан күз алмаларын эзләп тап... 33) Таптыңмы? 34) Шушы күзләре белән сөйләшә ул якты дөнья белән... 35) Шушы күзләре белән сөенә, шатлана, дөнья бәндәсенә әверелә. 36) Бу вакытта алтынсу төскә керә ул. 37) Борчылганда да шушы күзләр белән кайгыра, боега, сагына... 38) Борчылган вакытта бу күз алмаларын караңгы элпә каплап китә. 39) Аның өстенә мөлдерәп торган яшь тамчысы куна. 40) Шул тамчы гөлнең җан ачыгысы була да инде...

41) ... Бу юлы мин аны үзем эзләп таптым. 42) Фатирына ук барып кердем. 43) Берничә көн күренми торды шул ул.

44) Сәерсенеп кенә ачты Җиһан әби. 45) Танып алуга ук киң итеп елмаеп җибәрде, үз итеп аркамнан сөйде, аннары түргә дәште <...> артсыз урындыкның читенә генә утырып, дога кылды... 46) Аның мондый мөнәсәбәтен тою күңелгә нindидер, әлегә таныш түгел бер рәхәтлек бирә иде. 47) Мин үземне чын мәгънәсендә бәхетле кеше итеп тойдым. 48) Кешегә күп кирәкмени?! 49) Әә, юк... 50) Кешегә, бәхетле булу өчен, шундый күп кирәк! 51) Шушы япа-ялгыз, сәер карчыкның үз итүе, хөрмәтләп, яратып каравы кирәк!

(*Г. Гыйльмановтан*)

**28.** Текстның төп эчтәлеген чагылдырган җөмләне күрсәтегез.
1) Гөленә үрелгән идем дә, бирмәде.
2) Ниндидер чиста, ягымлы, иманлы карчык бу.
3) – Сез миңа шушы гөлегез хакында сөйләргә булган идегез...
4) ... Бу юлы мин аны үзем эзләп таптым.

**29.** Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләне күрсәтегез.
1) Ул да мине күрде, тыйнак кына елмаеп, ерактан ук башын кагып куйды.
2) Таеп егылмасын дип, аны подъезд төбенә кадәр барып алдым.
3) Юк, зарланмый иде Җиһан әби.
4) Ә менә җаны хакында дөрес әйттем.

**30.** Сөйләм теле лексикасы кулланылган очракны күрсәтегез.
1) гаҗәеп матур дөньяда яши (14 нче җөмлә)
2) алтынсу төскә керә (36 нчы җөмлә)
3) җан ачыгысы була да инде... (40 нчы җөмлә)
4) сәер карчыкның үз итүе (51 нче җөмлә)

## 2 нче өлеш

***Әлеге өлештәге биремнәрне үтәгәндә, үз җавапларыгызны 1 нче номерлы җавап бланкында 31-38 нче саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка языларга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда, буш шакмаклар калдырырга ярамый.***

***31–33 нче биремнәргә җавапларны сүзләр белән языгыз.***

**31.** 16-25 нче җөмләләр арасыннан парлы сүзне табып, текстта бирелгән формада күчереп алыгыз.

**32.** 26-35 нче җөмләләрдән синонимнарны табып, текстта бирелгән формада күчереп алыгыз.

**33.** 45 нче җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз.

***34 - 38 нче биремнәргә җавапларны цифр белән күрсәтегез.***

**34.** 1-7 нче җөмләләрдән рус теленән кергән алынма сүз кулланылган җөмләнең номерын языгыз.

**35.** 8-17 нче җөмләләрдән инфинитив кулланылган җөмләнең номерын языгыз.

**36.** 8-25 нче җөмләләрдән эндәш сүз кулланылган җөмләнең номерын языгыз.

**37.** 6-16 нчы җөмләләрдән тезмә кушма җөмләнең номерын языгыз.

**38.** 26-40 нчы җөмләләрдән кире сүз тәртибе күзәтелгән җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.

| |
|---|
| ***Барлык җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз.*** |

## 3 нче өлеш

| |
|---|
| ***Әлеге өлешкә җавапны 2 нче номерлы бланкта эшләгез. Башта биремнең номерын күрсәтегез (39), аннан соң инша языгыз.*** |

**39.** Текст нигезендә инша (сочинение) языгыз.

Текст авторы тәкъдим иткән проблемаларның берсен формалаштырыгыз һәм аңлатыгыз (цитаталар китерү белән артык мавыкмагыз).

Автор (хикәяләүче) позициясен формалаштырыгыз. Укылган текст авторының фикерләре белән килешү яки килешмәвегезне языгыз, сәбәбен аңлатыгыз. Үз җавабыгызны, беренче чиратта, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләрегезгә нигезләнеп дәлилләгез (беренче ике дәлил игътибарга алыначак).

Иншаның күләме 150 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка нигезләнмичә язылган эш бәяләнми. Әгәр инша сөйләп чыгу яки чыганак текстны теге яки бу аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Иншаны пөхтә, аңлашылырлык итеп языгыз.

## Татар теленннән имтихан эшен бәяләү системасы

### 1 нче өлеш

1 нче өлешнең һәм биремендәге дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.

Ике һәм күбрәк (шул исәптән дөрес җавап та), хата җавап яки җавап булмаса, 0 балл куела.

| Бирем номеры | Җавап | Бирем номеры | Җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 16 | 2 |
| 2 | 4 | 17 | 4 |
| 3 | 3 | 18 | 3 |
| 4 | 4 | 19 | 3 |
| 5 | 4 | 20 | 1 |
| 6 | 2 | 21 | 1 |
| 7 | 4 | 22 | 2 |
| 8 | 1 | 23 | 4 |
| 9 | 3 | 24 | 2 |
| 10 | 1 | 25 | 3 |
| 11 | 2 | 26 | 4 |
| 12 | 3 | 27 | 3 |
| 13 | 4 | 28 | 2 |
| 14 | 1 | 29 | 1 |
| 15 | 4 | 30 | 3 |

### 2 нче өлеш

| Бирем номеры | Җавап |
|---|---|
| 31 | кайгысызары |
| 32 | сөенә, шатлана |
| 33 | өтер |
| 34 | 3 |
| 35 | 16 |
| 36 | 23 |
| 37 | 7 |
| 38 | 28, 30, 34, 36 |

# 3 НЧЕ ӨЛЕШНЕҢ СЫЙФАТЛАМАСЫ

| **Текст турында мәгълүмат** |
|---|
| Чыганак: Г.Гыйльманов. Гөлләр дә елый.– https://yalkyn.ru/news/ijat/gollr-d-elyy |

| **Төп проблемалар** | **Автор позициясе** |
|---|---|
| Җир йөзендәге тереклек дөньясының кешеләр белән уртаклыгы бар. | Тормыш артыннан куудан туктап, табигатькә күз салу кеше өчен файдалы. |
| Кешегә бәхетле булырга күп кирәкми. | Кешене белми торып, аның турында фикер йөртү дөрес түгел. |

1) Гөл күтәреп килеп чыккан Җиһан әбине мин күтәренке күңел белән, шатланып көтеп алдым. 2) Ул да мине күрде, тыйнак кына елмаеп, ерактан ук башын кагып куйды. 3) Таеп егылмасын дип, аны подъезд төбенә кадәр барып алдым. 4) Гөленә үрелгән идем дә, бирмәде. 5) Артык ялынмадым, үзе беләдер әле дип, аның бу кирелеген эчемнән генә үткәреп җибәрдем.

6) – Менә шулай көн саен чыгып йөрибез... 7) Мин торган якка кояш карамый бит, көн яктысы төшми.

8) Юк, зарланмый иде Җиһан әби. 9) Гомумән, зарлана белми, ахры, бу карчык. 10) Аның һәр сүзе дога кебек ягымлы чыга. 11) Хәтта зары да... 12) Нииндидер чиста, ягымлы, иманлы карчык бу. 13) Нигә элгәрерәк белмәдем икән мин аны? 14) Бик кызык, гаҗәеп матур дөньяда яши бугай ул. 15) Нииндидер якты, илаһи бер халәттә...

16) – Сез миңа шушы гөлегез хакында сөйләргә булган идегез... 17) Аны тере дип тә әйттегез әле...

18) – Әә, әйе шул. 19) Әллә ни зур сере юк аның. 20) Ә менә җаны хакында дөрес әйттем. 21) Тере гөл бу. 22) Кешеләрдәге кебек, аның да җаны бар, күңеле бар, кайгысы-зары, шатлыгы бар...

23) – Каян беләсез соң аны, Җиһан әби?

24) – Күзләренә карап...

25) – Ничек инде? Гөлләрнең күзләре буламыни?

26) – Була шул. 27) Их сез, яшьләр... 28) Якыннарыгызның күзенә тутырып карарга да вакытыгыз юк бит сезнең. 29) Ә һәр үләннең, һәр үсемлекнең, гөлнең, чишмәнең, елганың, тауның, кояш-йолдызларның күзенә карарга бөтенләй дә вакытыгыз калмый... 30) Менә кара әле бу чәчәкләргә... 31) Менә таҗларына, керфекләренә кара... 32) Ул керфекләр арасыннан күз алмаларын эзләп тап... 33) Таптыңмы? 34) Шушы күзләре белән сөйләшә ул якты дөнья белән... 35) Шушы күзләре белән сөенә, шатлана, дөнья бәндәсенә әверелә. 36) Бу вакытта алтынсу төскә керә ул. 37) Борчылганда да шушы күзләр белән кайгыра, боега, сагына... 38) Борчылган вакытта бу күз алмаларын караңгы элпә каплап китә. 39) Аның өстенә мөлдерәп торган яшь тамчысы куна. 40) Шул тамчы гөлнең җан ачыгысы була да инде...

41) ... Бу юлы мин аны үзем эзләп таптым. 42) Фатирына ук барып кердем. 43) Берничә көн күренми торды шул ул.

44) Сәерсенеп кенә ачты Җиһан әби. 45) Танып алуга ук киң итеп елмаеп җибәрде, үз итеп аркамнан сөйде, аннары түргә дәште <...> артсыз урындыкның читенә генә утырып, дога кылды... 46) Аның мондый мөнәсәбәтен тою күңелгә нииндидер, әлегә таныш түгел бер рәхәтлек бирә иде. 47) Мин үземне чын мәгънәсендә бәхетле кеше итеп тойдым. 48) Кешегә күп кирәкмени?! 49) Ә, юк... 50) Кешегә, бәхетле булу өчен, шундый күп кирәк! 51) Шушы япа-ялгыз, сәер карчыкның үз итүе, хөрмәтләп, яратып каравы кирәк!

( *Г. Гыйльмановтан*)

## Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен (81 код) имтихан эшен бәяләү критерийлары

| № | *Бәяләү критерийлары* | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| **К1** | **Чыганак тексттагы проблемаларны формалаштыру** | |
| | Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен (теге яки бу формада) дөрес формалаштырган.<br>Проблеманы аңлау яки формалаштыруга бәйле фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен дә дөрес формалаштыра алмаган. | 0 |
| **К2** | **Чыганак текстның формалаштырылган проблемасын аңлату** | |
| | Имтихан бирүче формалаштырган проблема чыганак текстка нигезләнеп аңлатылган. Язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле фактик хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүче формалаштырган чыганак текст проблемасы аңлатылган,<br>**ләкин**<br>чыганак текстка нигезләнмәгән<br>**яки**<br>язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1 фактик хата бар. | 1 |
| | Имтихан бирүче формалаштырган проблема аңлатылмаган,<br>**яки**<br>язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1дән артык фактик хатасы бар,<br>**яки**<br>имтихан бирүче формалаштырмаган башка проблема аңлатылган,<br>**яки**<br>аңлатмалар урынына язмада текстның яки аның өзегенең эчтәлеге генә бирелгән,<br>**яки**<br>аңлатмалар урынына чыганак тексттан күләмле өзек кенә | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | китерелгән. | |
| **К3** | **Чыганак текст авторының позициясен чагылдыру** | |
| | Имтихан бирүче чыганак текст авторының (хикәяләүченең) аңлатылган проблемага бәйле позициясен дөрес формалаштырган.<br>Чыганак текст авторының позициясен аңлауга бәйле фактик хаталар юк.<br>Автор позициясен аңлауда фактик хаталар юк. | 1 |
| | Чыганак текст авторының позициясе имтихан бирүче тарафыннан дөрес формалаштырылмаган,<br>**яки**<br>чыганак текст авторының позициясе формалаштырылмаган. | 0 |
| **К4** | **Имтихан бирүченең проблемага карата үз фикерен дәлилләве** | |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (**2 дән ким булмаган дәлил китергән, шуларның берсе матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка карый**). | 3 |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, **2 дән ким булмаган** дәлил китергән),<br>**яки**<br>**матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка караган 1 генә дәлил китергән**. | 2 |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып дәлилләгән (**1** дәлил китергән). | 1 |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, **ләкин дәлилләмәгән,**<br>**яки**<br>имтихан бирүче фикере формаль рәвештә генә (мәсәлән, “Мин автор фикере белән риза / риза түгел”) бирелгән,<br>**яки**<br>имтихан бирүче фикере язмада бөтенләй чагылыш тапмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| **К5** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **К6** | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада имтихан бирүченең фикере төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| **К7** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **К8** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **К9** | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| **К10** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| **К11** | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| **К12** | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк | 1 |
| | Фактик хаталары бар | 0 |
| | **Язма эш өчен максималь балл** | **23** |

Грамоталылыкны (К7-К10) бәяләгәндә, укучы язмасының күләме исәпкә алына. Таблицада күрсәтелгән бәяләү нормалары күләме 150-300 сүздән торган язмаларны бәяләү өчен тәкъдим ителә.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән кимрәк булса, андый эш 0 балл белән бәяләнә, бирем үтәлмәгән булып санала.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән 150 сүзгә кадәр күләмдә булса, К7-К10 нчы критерийлардагы хаталары киметелә. **Бу критерийлар буенча 2 балл түбәндәге очракларда куела:**

К7 – орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар);

К8 – тыныш билгеләренә кагылышлы хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар).

**Бу критерийлар буенча 1 балл түбәндәге очракларда куела:**

К7 – хатасы 2 дән артык түгел;

К8 – 1-3 хатасы бар;

К9 – грамматик хаталары юк;

К10 – сөйләмгә кагылышлы хаталары 1 дән артык түгел.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән 150 сүзгә кадәр күләмдә генә булса, К7-К12 критерийлары буенча югары балл бөтенләй куелмый.

Әгәр укучының язмасында автор текстының эчтәлеге генә чагылыш тапса яки автор тексты бернинди аңлатмаларсыз күчереп кенә алынган булса, К1-К12 нче критерийлары буенча бу эш 0 балл белән бәяләнә. Чыганак текстка нигезләнмичә язылган эш бәяләнми.